**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№1136**
**10.03.2020**

Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерү һәм җыештыру буенча санитар-экологик ике айлык үткәрү турында

Шәһәр территориясенең тиешле санитар, эстетик торышын тәэмин итү һәм аны киләчәктә төзекләндерү максатында, Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/8 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. 2020 елның 1 апреленнән 2020 елның 31 маена кадәр Яр Чаллы шәһәре территориясен төзекләндерү һәм җыештыру буенча санитар-экологик ике айлык (алга таба – ике айлык) үткәрергә.

2. Ике айлыкны оештыру һәм үткәрү буенча шәһәр штабы составын (алга таба – шәһәр штабы) кушымтада каралганча расларга.

3. Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсенә 2020 елның 20 мартына кадәр ике айлыкны үткәрү планын расларга.

4. Башкарма комитетның районнар хакимияте Башлыкларына Яр Чаллы шәһәренең тиешле район территорияләрендә ике айлыкны оештыру һәм үткәрү буенча район штаблары төзергә һәм атна саен ике айлык барышы турында шәһәр штабына мәгълүмат тапшырырга.

5. Яр Чаллы шәһәре оешмалары җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

1) җир законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелгән җир участокларындагы территорияләрне санитар җыештыруны тәэмин итәргә;

2) район штабларына ике айлыкны оештыру һәм үткәрү буенча хисап тапшырырга.

6. Шәһәр штабына район штабларының ике айлыкны үткәрү планының үтәлеше турындагы мәгълүматын тыңларга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев